**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

28.02.2020 № 102

**Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзасының үз вәкаләтләрен үтәүне вакыты җитмичә туктатуы сәбәпле, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 23 һәм 29 статьялары һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 12 һәм 18 статьялары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзасы итеп вакантлы урынга кую өчен кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турындагы кушымтада бирелүче белдерү текстын расларга һәм аны «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсенә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны, 2020 елның 18 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентына бирергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе Ә.Ә. Сәфәровка йөкләргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «28» февралендәге
102 номерлы боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзасы итеп вакантлы урынга кую өчен кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турында
белдерү

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасының үз вәкаләтләрен үтәүне вакыты җитмичә туктатуы сәбәпле, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 23 һәм 29 статьялары һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 12 һәм 18 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзасы итеп вакантлы урынга кую өчен кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул ителә.

Тәкъдимнәр һәм аларга теркәп бирелүче, закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар әлеге белдерү рәсми басылып чыккан көннән 2020 елның 13 мартына кадәр, шимбә, якшәмбе һәм ял көне булган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420014, Казан шәһәре, Кремль, 5 корпус, 203 кабинет, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты (Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе), элемтә өчен телефон 8 (843) 567-89-95.